# ЗАКОН
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в статьи 1 и 3 Закона Республики Татарстан «Об использовании лесов в Республике Татарстан»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
24 декабря 2021 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 22 мая 2008 года № 22-ЗРТ «Об использовании лесов в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2008, № 5 (I часть); 2009, № 12 (I часть); 2011, № 6 (I часть); 2012, № 1, № 12 (I часть); 2013, № 12 (I часть); 2014, № 5, № 12 (II часть); 2015, № 11 (I часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2016, № 40 (часть I); 2017, № 27 (часть I); 2018, № 44 (часть I); 2019, № 2 (часть I); 2020, № 1 (часть I); 2021, № 57 (часть I), № 93 (часть I) следующие изменения:

1) пункт 6 статьи 1 после слов «своевременного представления» дополнить словами «в форме электронного документа»;

2) в статье 3:

а) часть 2 дополнить пунктом $9^1$ следующего содержания:

«$9^1$) принятие решений о создании, об упразднении лесничеств, создаваемых в их составе участковых лесничеств, расположенных на землях, указанных в пункте 4 части 2 статьи 23 Лесного кодекса Российской Федерации (в отношении особо охраняемых природных территорий регионального значения), установлении и изменении их границ;»;

б) в части 3:

пункт 2 признать утратившим силу;

дополнить пунктом $10^1$ следующего содержания:

«$10^1$) выдача разрешения на строительство в случае осуществления строительства, реконструкции объектов капитального строительства, расположенных на землях лесного фонда, которые допускаются к строительству на них при использовании лесов для осуществления рекреационной деятельности, в соответствии с лесным законодательством, а также выдача разрешения на ввод указанных объектов в эксплуатацию;»;

пункт 12 признать утратившим силу;

в пункте 13 слова «, а также проведение на землях лесного фонда лесоустройства, за исключением случаев, предусмотренных пунктами 1 и 2 части 1 статьи 68 Лесного кодекса Российской Федерации» исключить;

в пункте $13^4$ слова «частью 4» заменить словами «частью 3»;

в пункте $13^6$ слова «, размещение его на официальном сайте уполномоченного органа в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет» и направление его в уполномоченный Правительством Российской Федерации федеральный орган исполнительной власти» исключить;

дополнить пунктом $13^{11}$ следующего содержания:

«$13^{11}$) осуществление мероприятий по лесоустройству в отношении лесов и лесных участков, находящихся в собственности Республики Татарстан;».

**Статья 2**

1. Настоящий Закон вступает в силу с 1 января 2022 года, за исключением положений, для которых настоящей статьей установлены иные сроки вступления их в силу.

2. Абзацы третий и четвертый подпункта «б» пункта 2 статьи 1 настоящего Закона вступают в силу с 1 марта 2022 года.

3. Пункт 1 и абзац пятый подпункта «б» пункта 2 статьи 1 настоящего Закона вступают в силу с 1 января 2023 года.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
27 декабря 2021 года
№ 102-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законының 1 һәм 3 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 24 декабрендә
кабул ителде

## 1 статья

«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 1, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (II өлеш); 2015, № 11 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 44 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш); 2021, № 57 (I өлеш), № 93 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның 6 пунктында «хисапны» сүзеннән соң «электрон документ рәвешендә» сүзләрен өстәргә;

2) 3 статьяда:

а) 2 өлешкә түбәндәге эчтәлекле $9^1$ пункт өстәргә:

«$9^1$) Россия Федерациясе Урман кодексының 23 статьясындагы 2 өлешенең 4 пунктында күрсәтелгән җирләрдә урнашкан урманчылыкларны, алар составында төзелә торган участок урманчылыкларын төзү, бетерү (региональ әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләренә карата), аларның чикләрен билгеләү һәм үзгәртү турында карарлар кабул итү;»;

б) 3 өлештә:

2 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле $10^1$ пункт өстәргә:

«$10^1$) урман фонды җирләрендә урнашкан, урманнардан рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдаланганда урман фонды җирләрендә урман законнары нигезендә төзү өчен рөхсәт ителә торган капиталь төзелеш объектларын төзүне, реконструкцияләүне гамәлгә ашыру очрагында төзелешкә рөхсәт бирү, шулай ук күрсәтелгән объектларны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү;»;

12 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

13 пунктта «, шулай ук, Россия Федерациясе Урман кодексының 68 статьясындагы 1 өлешенең 1 һәм 2 пунктларында каралган очраклардан тыш, урман фонды җирләрендә урман төзелешен» сүзләрен төшереп калдырырга;

$13^{4}$ пунктта «4 өлеше нигезендә» сүзләрен «3 өлеше нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

$13^{6}$ пунктта «, аны вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтына урнаштыру һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органына җибәрү» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле $13^{11}$ пункт өстәргә:

«$13^{11}$) Татарстан Республикасы милкендәге урманнарга һәм урман кишәрлекләренә карата урман төзелеше чараларын үткәрү;».

**2 статья**

1. Әлеге Закон, шушы статьяда үз көчләренә керүнең бүтән сроклары билгеләнгән нигезләмәләреннән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пунктының «б» пунктчасындагы өченче һәм дүртенче абзацлары 2022 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

3. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пункты һәм 2 пунктының «б» пунктчасындагы бишенче абзацы 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 27 декабрь
№ 102-ТРЗ